Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

18 май, 2023 ел № 233

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклап калу һәм аларга ярдәм итү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру, Питрәч муниципаль районында яшәүче халыкларның этномәдәни һәм рухи үсеше өчен шартлар тудыру максатларында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм яклау турындагы мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында милли мәдәниятләрне һәм традицияләрне саклау һәм аларга ярдәм итү турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына:

- «2021-2026 елларга Питрәч муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» программасы чараларын үтәүне тәэмин итәргә;

- шәхеснең үз-үзен тормышка ашыру өчен өстәмә киңлек булдыру, балаларны, яшьләрне, халыкны үзебезнең рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи төп милли кыйммәтләрне торгызуга һәм саклауга җәлеп итү эшен активлаштырырга.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов